# Сарык белән кәҗә (экият)

## (Г.Тукай эзләреннән язылган экологик әкият)

Автор**: Башкортстан республикасы Илеш муниципаль районы Аккуз авылы муниципаль урта гомуми белем биру мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы Шәйхетдинова Дамира Мирсәгыйт кызы.**

Борын-борын заманда, үрдәк үрядник, этәч командир заманда түгел, безнең заманда, яшәгән, ди, бер әби белән бер бабай. Әллә кайда да түгел, Илеш районының бер күркәм авылында бакча утап, яшелчә үстереп, тавык асырап көн күргәннәр. Аларның ябык кына кәҗәсе белән сарыгы булган. Әллә картайганга, әллә кулларыннан эш киткәнгә, әби белән бабай бу малларын бер дә карый алмаганнар.

- «Әйдә, без бу малларны чыгарып җибәрик.Үз көннәрен үзләре күрсеннәр»,-дигән бабай беркөнне. Әби ризалыгы белән кәҗә белән сарыкка хәер сораша торган зур капчык тоттырып, авылдан-авылга йөрергә кушып чыгарып җибәргәннәр, ди.

Ә сарык, халык телендә бик аңгыра булса да, бу дөньяда бик күп гомер иткән булган. Акыллы сарык булган бу. Әйткән сарык кәҗәгә:

- «И, кәҗә дустым. Хәер эстерәп йөрмик. Әйдә бер булса урманга барыйк. Яшеллектә ризык бетмәс, тамагыбыз шунда туяр».

Киткәннәр, ди, болар куе урманга карап. Табигатьнең матурлыгы авыл мал- туарына инде гаҗәп түгел. Тирә яктагы чүп-чар хушларын алган боларның: пластик шешәләр, консерва банкалары, мал сөяк-санагы, пыяла ватыклары урман авызын ямансу һәм кызганыч бер моңга күмгән. Сарык белән кәҗә әллә ни аптырамаган, бу чүп-чардан җирне арындырырга ашыккан. Капчыкларын ачканнар да шешәләрне, сөякләрне, пыяланы шунда тутырганнар. Киткәннәр, ди, урманга кереп, тәмле усак кайрысы, хуш исле печән эзләп. Баралар, баралар. Каршыларында бер көтү ач бүре, учак ягып

ботка пешерергә чамалап утыра, ди. Бүреләр кәҗә белән сарыкны күргәч бик сөенгәннәр:

-Әһә, туя икән тамагыбыз! - диешкәннәр.
Кәҗә,бу хәлләрне сизеп калып, әллә бәләкәй генә башы эшләп киткән, әллә ул да Г.Тукай әкиятен укыган булган. Әллә сакалы буллу сэбаплы , чынлап та аксакал акылына ия булган да куйган. Кәҗә болай дип сөрән салган:
- Тамак туяр бүген, мәкә-кә-кә. Яле ,сарык, теге бүре кабыргаларын чыгар капчыктан, ялап карыйк. Җиденче бүрене чәнчеп чалган ватык шешәне дә чыгар!- дигән.

Сарык кабалана-кабалана чүп-чар тутырылган капчыкны актарып, ватык шешәне, сөякләрне чыгарган.
Буреләр, моны күреп, куркуга сабышканнар. Олы карт бүре калтырана-калтырана:
« Боткага май да кирәк булыр. Үткән атнада чәчәкле аланда бәндәләр ит ыслап ял иткән урында, пластик шешәдә усемлек мае калган иде. Шуны алып килим әле»,- дип моннан ычкыну ягын караган.
Бүреләр, мең төрле сәбәп табып төрлесе төрле якка табанын ялтыраткан. Казан белән ботка янында кәҗә белән сарык кына торып калган.
Алар, ике уйлап тормаган, казан белән сыйны күтәреп, авылга әби белән бабайны сыйларга юнәлгәннәр.
Әби белән бабай, сарык белән кәҗәне рәнҗетеп куып чыгарганнарына үкенеп, бик кайгырышып, елап утырганнар икән. Малларының исән кайтканнарына бик сөенгәннәр. Аларның әдәпле, экологик чисталык өчен көрәшүче булуына куанганнар.
Әле дә бик матур итеп яшәп яталар,ди. Тик сарык белән кәҗә генә көн дә табигатьне күзәтеп, урман тирәсенә барып, чүп-чар булмавын кайгырта. Ял итүчеләр булса, чүп ташламауларын кисәтә. Кәҗә мөгезләрен күрсәтә:

-«Мәкә-кә, мәкә-кә-кә.Табигатьне чиста тоту гадәттә",- дип кычкыра икән.
Ә сарык исә:

-«Бә-бә-бә, чүп ташлама син бәндә»,- ди икән.
Шулай, дуслар, хәзерге заманда, ватык шешә ярчыгы да бүре башы бәрәбәренә ия икән. Әкиятем дә тәмам.

Кулланылган әдәбият:

1.Г.Тукай «Кәҗә белән Сарык» хикәясе